# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXXVII СЕССИЯСЕ

## КАРАР № 213

Мөслим авылы «13» декабрь 2024 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы депутатларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2024 елның 29 маендагы 188 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата хезмәт хакын 2025 елның 1 нче гыйнварыннан 1,05 тапкырга арттырырга һәм Мөслим муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны булдыру нормативлары турында» 2024 елның 29 маендагы 188 номерлы карары белән расланган Мөслим муниципаль районындагы муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карар нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,05 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 13990 сум күләмендә билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р. Г. Гариповка йөкләргә.
5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р. Хуҗин